**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2021елның 25 октябре** **87-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьев авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 11 февралендәге 96-РС номерлы үзгәрешләр белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 61-РС номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын аерып чыгару, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә;

2. Гавами тыңлаулар уздыру чорын - кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итү мизгеленнән алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы кимендә бер айдан ким өч айдан артык була алмый;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Башкарма комитетына:

3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган гавами тыңлауларның башлануы турында хәбәр әзерләргә;

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 14 эш көне эчендә әлеге карарның 3.1 п. күрсәтелгән хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы уставында билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) кирәк.;

3.3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән чорда гавами тыңлаулар уздырырга;

3.4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне, гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә, ахыргы карарны кабул итү өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә.

4. Әлеге карарны "Кама ягы"(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә).

6. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**